| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

«30» декабря 2022г. с. Тюлячи № 298

Теләче муниципаль районының 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләре исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 74.1 статьясы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районының 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләре исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Житәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Житәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» 12 2022 № 298
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләре исемлеге**

| № т/б | Гавами норматив йөкләмә исеме | Ачык йөкләм барлыкка килүнең хокукый нигезе | | | | Түләү төре | Норматив хокукый актта билгеләнгән түләү күләме (исәпләү тәртибе) | Алучылар категориясе | Башкаручыларның исемнәре | БК буенча чыгымнар коды |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төр | Дата | Номер | Атамасы | | | | | |
| 1. | Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары | Теләче муниципаль районы Башлыгы карары (17.10.2017 № 53, 23.11.2020 № 25, 27.01.2021 № 3, 02.02.2021 № 4 карарлар редакциясендә) | 10.01.2007 | 1 | Торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында | Компенсация түләве | Исәп-хисап | Мәдәният хезмәткәрләре | Теләче муниципаль районы бюджет учреждениеләре | 80508010830144090112212, 80508010840144091112212, 80508010810144090112212 |
| 2. | Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларны тәрбияләгән һәм | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары | 23.09.2013 | 453 | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары | Компенсация түләве | Исәп-хисап | Балаларның ата-аналары (законлы | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты | 80510049900013200313262 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә компенсация түләү | | | | булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында | | | вәкилләре) | | |
| 3. | Опекада (попечительлектә) торучы баланы матди карап торуга, тәрбиягә бала алучы гаиләдә тәрбияләнүгә түләүләр | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы | 28.12.2022 | 300 | Тәрбиягә бала алучы гаиләләргә һәм опекага (попечительлеккә) тапшырылган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга айлык түләүләрне гамәлгә ашыру турында | Компенсация түләве | Исәп-хисап, фиксацияләнгән | Опекуннар (попечительләр), тәрбиягә алган ата-аналар | МКУ "Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге" | 80510040350323110313262, 80510040350323130313262 |